ISSN 0868-8001 16+

№ 7 (1127) / 2025

МӘГАРИФ

- Мәгариф министрлары форумы. Яңа мөмкинлекләр
- Учителей в обиду не дадим!
- «Адымнар – Чаллы» гимназиясе мөгаллимнәре презентациясе



Азат ГАЛИЕВ:

«АНА ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУГА МОТИВАЦИЯ ТУДЫРАБЫЗ»

ЭЧТӘЛЕК / СОДЕРЖАНИЕ

Фәния ЛОТФУЛЛИНА
Мәгариф министрлары форумы. Яңа мөмкинлекләр ____ 2

Гузель КАМАЛОВА
Учителей в обиду не дадим! ____ 8

Вакыйгалар календаре ____ 12

Альберт САБИР
Азат ГАЛИЕВ: «Ана телендә белем алуга мотивация тудырабыз» ____ 14

Гульназ КАПИТОНОВА
Вчера – выпускники, сегодня – педагоги ____ 21

Мөршидә КЫЯМОВА
Энциклопедия язу җиңел эш түгел! ____ 25

Эльмира САЙФЕТДИНОВА
Женщины Золотой Орды ____ 28

Мөршидә КЫЯМОВА
Ярты гасырга сузылган остазлык юлы ____ 33

Ләлә МОРТАЗИНА
Каракалпак әлифбасын төзегән татар мәгърифәтчесе ____ 37

Люция ГЫЙНИЯТУЛЛИНА
Тәэминә Биктимерова: «Татар хатын-кызларының белемле булуын күрсәтәсем килде» ____ 40

Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ
Нигъмәткә хөрмәт ____ 43

Зөлфия МАНСУРОВА
Музей педагогикасы ____ 46

Лилия ХАРМАТУЛЛИНА
Методы развития креативного мышления на уроках труда ____ 48

Эльмира БАРЕЕВА
Дифференциация понятий «слово», «словосочетание», «предложение». Признаки предложения ____ 50

Азиля НАЗМИЕВА
Применение правил правописания: сочетания ЧК – ЧН, ЧТ, ЩН ____ 53

Гөлназ МАХИЯНОВА
Хәл фигыльне өйрәнүдә интерактив-уен технологияләре куллану ____ 56

Рамиля ЧУРАГУЛОВА
Образ мака в рассказах Е. Носова «Живое пламя» и А. Еники «Цветок мака» ____ 58

Гульшат КАБИРОВА
Наш мир / мой мир. («Our/my world») ____ 63

Ляйсан ШАНГАРЕЕВА
Crime Writers – Agatha Christie.
Писатели-криминалисты. Агата Кристи ____ 66

Алина ВАСИЛЬЕВА
Сосудистая система ____ 71

Гөлнар КИТАЕВА, Венера ТАҺИРОВА
«Мисс һәм Мистер «Адымнар» ____ 74

Зульфия ГАЙНУТДИНОВА
Методы и приемы формирования и становления навыков письма в 1 классе ____ 76

Галина ОВЧИННИКОВА
Смутное время. На пути к единению ____ 79

Гульназ ШАЙСУЛТАНОВА
Архимедова сила. Закон Архимеда ____ 82

Фарида МУРТАЗИНА
Похлебка по-лаишевски ____ 84

Инзия ГЫЙБАДУЛЛИНА
«Алтын хыял фест» ____ 88

Мөршидә КЫЯМОВА
Каләмне штыкка тиңләүчеләр ____ 91

Алия САДРИЕВА
Туган җир җырчысы ____ 94

Июль аенда истәлекле көннәр ____ 96











forumedu.press

Мәгариф министрлары форумы. Яңа мөмкинлекләр

«Татарстанда мәгариф буенча алып барылган эшләр бу өлкәдәге мәсьәләләрне хәл итү өчен нигез булырга тиеш», – дип билгеләде Россия Президенты Владимир Путин «Киләчәкне формалаштырып» халыкара мәгариф министрлары форумында катнашучыларга мөрәҗәгатендә.

Инде менә өченче ел Казанда шундый әһәмиятле чара уздырыла. Быел форум катнашучы илләр саны буенча иң масштаблысы булды: бирегә Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Белоруссия, Абхазия, Көньяк Осетия, Мьянма, Лаос һәм башка дәүләтләрне дә исәпкә алганда, 35 тән артык илдән вәкилләр һәм мәгариф министрлары килде.

БЕЛЕМ БИРҮ СЫЙФАТЫН ЯҢАЧА БӘЯЛӘҮ

– Биредә уртак омтылышлар белән җыелдык. Безгә бергәләп барлык милли мәгариф системалары очраша торган катлаулы зур сынауларга җавап эзләргә, глобаль тенденцияләрне исәпкә алырга кирәк. Инде мәгариф системасына җитди үзгәрешләр керткән цифрлы технологияләр һәм ясалма интеллект таралышы шулар арасында. Һәм әлбәттә, мәктәпләрне, көллиятләрне, университетларны илебез үсешенең агымдагы һәм перспектив бурычларын хәл итүгә нәтиҗәле әзерләргә кирәк, – дип башлады сүзен традиция буенча РФ Президенты Владимир Путин пленар утырыш ачылышындагы мөрәҗәгатендә. – Шул ук вакытта мәгарифнең милли тиңдәшлекне саклап калуга хезмәт итүе, мәдәниятләр-



tatar-inform.ru

Форумның пленар утырышын РФ мәгариф министры Сергей Кравцов алып барды

нең һәм традицияләрнең күптөрлелеген хуплавы мөһим. Шуңа күрә мәктәп, киң мәгънәсендә иң алдынгы белем һәм компетенцияләр биреп кенә калмыйча, яшь кешегә тормышта ныклы кыйммәтләргә таяна алырлык гармонияле шәхес булып танылырга ярдәм итәргә тиеш.

Видеосәламләүне РФ Тышкы эшләр министры Сергей Лавров та яздырып җибәргән иде. Аның сүзләренчә, хакимият чит илдә рус телен өйрәнү мөмкинлекләрен киңәйтүне дәвам итәчәк. Чөнки ул – Россиядә белем алуга ачкыч, шул исәптән РФ Хөкүмәтенең чит ил гражданнары өчен квоталары кысаларында. Исегезгә төшерәбез: быел Россия югары уку йортларында белем алырга ниятләгән чит ил студентларын, мигрант балалары белән беррәттән, 1 апрельдән рус телен белүгә тест тапшырырга мәҗбүр иттеләр.

– Якын арада безнең ил иң әзерлекле чит ил абитуриентларына грант ярдәме тәкъдим итә алачак, – дип сөйләде Лавров. Элегрәк хәбәр ителгәнчә, Россия 2025 елда чит ил студентларына 2 мең грант бүлеп биргән иде.

Форум кысаларында Мәгарифне цифрлы трансформацияләү, укытуга ясалма интеллект технологияләрен кертү, инклюзив практикаларны үстерү, тәрбия һәм һөнәри юнәлеш бирү мәсьәләләре буенча экспертлар дискуссияләрен үз эченә алган бай эшлекле программа узды. Фикер алышуларның төп темасы белемгә, технологияләргә һәм мәдәни кыйммәтләргә тигез хокуклы юл булдыру, шулай ук төрле илләрнең мәгариф системалары алдында торган гомуми глобаль сорауларны хәл итү булды.

РФ мәгариф министры Сергей Кравцов хезмәттәшлекнең өстенлекле юнәлешләрен, шул исәптән белем бирү сыйфатын бәяләүнең объектив һәм катнашучы илләрнең милли үзенчәлекләренә хөр-



tatar-inform.ru

Россия Президенты ярдәмчесе Владимир Мединский чыгышын тарих фәнен укытуга багышлады

мәт принципларына нигезләнгән, PISA, PIRLS һәм TIMSS билгеләре үрнәгендә, яңа халыкара системасын булдыру инициативасы белән чыкты. Аның сүзләренчә, мондый система контроль түгел, ә үсеш коралы булачак, милли мәгарифнең көчле якларын ачыкларга ярдәм итәчәк, мәктәп укучыларын һәм студентларны әзерләү сыйфатын күтәрәчәк. Ул чараның елдан-ел масштабы зурайганын белдерде.

– Форумда катнашучы министрлар саны ел да арта бара. Биредә 50 ләп ил һәм 20 гә якын министр катнаша. Быел катнашучылар күбәйде, төрле илләрдән делегацияләр килде. Без аларга Россиянең мәгариф системасындагы заманча алымнар һәм ысулларын, педагогик университетлар һәм башка төр учреждениеләр эшчәнлеген күрсәтәбез. Шулай ук Халыкара «Артек» лагере тәҗрибәсен дә тәкъдим иттек. Киләчәктә узачак форумнарда катнашучыларның тагын да артуына өметләнәбез. Агымдагы елда форумга, мәсәлән, Абхазия, Көньяк Осетия мәгариф министрлары да килде. Африка, Латин Америкасы өчен дә форум кызыксыну уятты, – диде министр.

Шулай ук Кравцов төрле дәүләтләрдә рус телен өйрәнү өчен 60 үзәк ачылуын әйтте. Мәсәлән, Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә Мәскәүдәге Примаков мәктәбе базасында шундый бүлек ачылган.

– Россия рус теле укытучыларын чит ил мәктәпләренә җибәрергә әзер. Бу максатларга акча бар, кабул итүче як яшәү һәм транспортта йөрүне генә тәэмин итәргә тиеш. Форумга килгән министрлар белән эшлекле очрашулар, сөйләшүләр бара. Актив рәвештә меморандумнарга кул куела. Мондый килешүләр яңа мөмкинлекләр ачуына инанам, – дип сөйләде Кравцов.

Ул шулай ук башка илләргә, хәзер Россиядә колач җәюче, белем бирүдә ясалма интеллектны куллануның халыкара кодексын булдыруга кушылырга тәкъдим итте. Сүз уңаеннан ясалма интеллект үсешенә карата үз чыгышында Берләшкән Гарәп Әмирлекләренең мәгариф министры Сара әл-Әмири аерым басым ясады. Аның көндәлек тормышка йогын-

тысын исәпкә алырга, өстенлекләрне максималь файдаланырга, әмма үткәнне дә онытмаска кирәклеген кисәтте.

ТАРИХ ДӘРЕСЛЕГЕ ДӨНЬЯГА КАРАШКА НИГЕЗ САЛА

Берничә ел элек РФ Президенты тарих дәреслекләренең бердәм линейкасын эшләргә йөкләгән иде. Россия Президенты ярдәмчесе Владимир Мединский да үзенең чыгышын тарих фәнен укыту темасына багышлады. Мединский билгеләп үткәнчә, бу карар табигый, чөнки бердәм системадан башка имтиханнарга бертөрле әзерләнеп булмый. Ул вакытта тарих буенча дәреслекләрнең 16 томы эшләнде, шул исәптән ике ел элек өлкән сыйныфлар өчен дәреслекләр барлыкка килде. Барлык сыйныфлар өчен дә бер стильдә эшләнгән басмалар быел 1 сентябрьдән укучыларга таратылачак.

Линейканың беренче төп принцибы – дәвамчанлык. Авторлар дәреслекләрнең визуаль яктан һәм эчтәлеге буенча да совет һәм революциягә кадәрге чор традицияләрен саклап калырга тырыша. Икенчесе – дөнья һәм Россия тарихын синхронлаштыру. Һәр параграф бу вакытта Россиядә нинди вакыйгалар булганлыгы турындагы язмадан башлана. Шулай ук Совет чорында кертелгән кайбер идеологик төгәлсезлекләр дә төзәтелә. Укучыларга мәгълүматны кабул итү җиңелрәк булсын өчен, дәреслекне аңлаешлы тел белән чыгару да иң төп максатларның берсе булып тора.

– Моннан тыш, без «Тарих.РФ» порталында «Укытучыга һәм укучыга» дип аталган махсус бүлек булдырдык. Анда дәресләр, параграфлар буенча бүленеш нигезендә бик күп өстәмә материаллар куела. Тарихның безнең ил халыкларын аермавы гына түгел, ә аларны берләштерүе аеруча мөһим. Ата-бабаларыбызның илебез көчлерәк булсын, яхшырак яшәсен өчен бергәләп тырышканын без һәрчак истә тотарга тиеш. Бу – мәктәптәге тарих курсының төп бурычы, – дип билгеләде Мединский.

Ул 11 нче сыйныфлар өчен гомуми тарих буенча дәреслекләрнең тышлыкларын 2025 елның көзендә яңартырга җыенуларын да әйтте. Анда СССР һәм АКШ космик корабларының бер-берсенә тоташуы, СССР һәм Канада җыелма командасының хоккей матчы кадрлары сурәтләнәчәк.

Сүзен йомгаклап, ул, мәктәп дәреслеге укучының дөньяга карашына нигез сала, дигән фикерен белдерде.

– Әгәр дәүләт дәреслеккә башка илләр, халыкара фондлар һәм, имештер, төрле хәйрия оешмаларына язарга мөмкинлек бирсә, бу балаларның үскәч, безнең илнең дөньядагы ролен, аның тарихын һәм үз киләчәген ничек күз алдына китерәчәгенә гаҗәпләнмәгез, – дип ассызыклады спикер. Бу «тарихны акларга» һәм «кара тапларны яшерергә» кирәк дигән сүз түгел. Иң мөһиме – укучыны мөстәкыйль фикер йөртергә өйрәтү һәм шул вакытта «югары фальсификацияләр» белән башын катырмау.

ТАТАРСТАН ЛИДЕРЛАР РӘТЕНДӘ

Республика Рәисе Рөстәм Миңнеханов билгеләп үткәнчә, форумның бездә узуы – төбәк өчен зур мәртәбә.

– Республикада еш кына зур халыкара чаралар уздыру гадәткә керде. Татарстан берничә ел дәвамында мәгариф һәм фән өлкәсендә дә лидер булып кала. Бездә 6 меңнән артык белем бирү оешмасы эшли. Максатыбыз – үз-үзеңне үстерү өчен шартлар тудыру. Бүген ярдәм алган һәр талант бөтен ил өчен прогресс двигателе булырга мөмкин. Татарстанда уртак җитештерү оешмалары булдыру һәм инновацияләр кертү өчен илебездә иң яхшы инфраструктураларның берсе булдырылды. Без мирасыбызны саклап кына калмыйбыз, ә мәгарифтәге инновацияләр аша киләчәкне дә булдырабыз. Кискен трансформацияләр шартларында мәга-



mon.tatarstan.ru

Эсватини Корольлеге мәгариф һәм һөнәри әзерлек министры Овен Сабело Нксумало белән очрашу

риф һәм фән илләрнең тотрыклы үсешенең төп факторына әверелә. Бу форум да яңа идеяләр тууга этәргеч булачак, – дип сөйләде Татарстан Рәисе.

Аның сүзләренә караганда, бүген республикада 1935 мәктәпкәчә учреждение, 1432 гомуми белем бирү оешмасы, 2773 өстәмә белем бирү оешмасы, 100 һөнәри белем бирү оешмасы, Россиянең иң яхшы 100 уку йорты арасына кергән 3 университетны да кушып, 45 югары уку йорты эшли. Татарстан шулай ук мәгариф өлкәсендә берничә чит ил белән актив хезмәттәшлек итә – укучылар Россиянең һәм чит илләрнең иң яхшы мәгариф оешмаларында стажировка үтәләр.

КИЛЕШҮЛӘР

Форумның төп нәтиҗәләреннән берсе – дәүләтара килешүләргә кул кую булды. Мәсәлән, Россия һәм Сербия Республикасы арасында гомуми, урта һөнәри һәм өстәмә һөнәри белем бирү өлкәсендә хезмәттәшлек турында меморандум төзелде. Биредә рус телен өйрәнүне үстерүгә һәм һөнәри тәҗрибә алмашуга аерым басым ясалды. Россия һәм Корея Халык Демократик Республикасы арасында белем бирү үзәкләре булдыруны, рус һәм корея телләрен популярлаштыруны, олимпиадалар һәм уртак конкурслар уздыруны күздә тоткан, мәгариф өлкәсендә хезмәттәшлек турында килешүгә кул куелды.

Шулай ук «Алгоритмика» мәктәбе белән Төньяк Осетия – Алания Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы арасында хезмәттәшлек турында меморандум имзаланды. Документ төбәк педагоглары һәм мәктәп укучылары арасында информатиканы, мәгълүмати-коммуникацион технологияләрне һәм цифрлы күнекмәләрне үстерүгә һәм популярлаштыруга юнәлдерелгән. Моннан тыш, ул мәгълүмати технологияләр өлкәсендә мәктәп укучыларын һәм студентларны иртә һөнәри юнәлеш бирү инициативаларын да үз эченә ала. Яклар 1–11 нче сыйныф укучылары өчен белем

бирү чаралары һәм ярышлар үткәрүне, тәҗрибә уртаклашуны, шулай ук информатика буенча уку программалары, методик материаллар һәм цифрлы контент бирүне кертеп, төбәк инициативаларын бергәләп гамәлгә ашыру турында килештеләр. Бу ресурсларга керү махсус IT-платформа аша гамәлгә ашырылачак.

Килешү Төньяк Осетиядә цифрлы белем бирүне үстерүдә һәм цифрлы грамоталылыкны арттыруда бер адым булачак. Төньяк Осетия – Алания Республикасы мәгариф һәм фән министры Элла Алибекова үз чыгышында: «Без Россиядә мәгарифнең көчле системасын күрдек. Чит ил министрлары һәркемнең белем алуга мөмкинлеге булсын дип күп сөйләделәр. Аерым алганда, мине Абхазиянең үз тамырларын хәтерләве бик шатландырды, бу Көньяк Осетиягә дә кагыла. Бездә мәгарифнең совет системасына нигезләнүен хәтерлиләр», – диде.

«Просвещение» компаниләр төркеме президенты Михаил Кожевников ассызыклавынча, Казанда узган «Киләчәкне формалаштырып» халыкара мәгариф министрлары форумы яңа мөмкинлекләр ача.

– Биредә ышаныч мәйданчыгы формалаша: дәрәҗәле белгечләр мәгариф өлкәсе буенча үзләренең фикерләрен, позицияләрен, уртак максатларны, бурычларны һәм мөмкинлекләрне билгелиләр. Шулай итеп, бердәм программалар булдырыла. Үзара бәйләнешләр, һичшиксез, үзенең нәтиҗәләрен бирә, – дип билгеләде ул.

Шулай ук Кожевников форумның нәтиҗәле узуын әйтте. Алар Кыргызстаннан коллегалар белән хезмәттәшлекне дәвам итү хакында сөйләшкәннәр.

– Кыргызстан белән берлектә андагы мәктәпләр өчен рус теле дәреслекләре эшлибез. Кубадагы коллегалар белән Латин Америкасы өчен испан телендә дәреслекләр һәм аудиокитаплар ясарга нәшер итәргә ниятлибез. Шуңа күрә планнар зурдан, – дип сөйләде ул.

ТР мәгариф һәм фән министры урынбасары Андрей Поминов әйтүенчә, форумның Татарстан өчен дә файдасы зур булды. Күп кенә илләр конкрет юнәлешләр буенча хезмәттәшлек турында ике яклы килешүләр имзалау белән кызыксына. Әлегә алар киң җәмәгатьчелеккә ачылмый, әмма якын арада уртак проектларны гамәлгә ашыру буенча эш көтелә.

– Без илләрнең Россия мәгариф системасы, аерым алганда Татарстан белән кызыксынуы зур булуын күрәбез, – диде Андрей Поминов.

Делегатлар үзләренең мәгариф системасы һәм Россия белән хезмәттәшлек мөмкинлекләре турында сөйләделәр. Чит дәүләтләрнең мәгариф министрлары күбесенчә халыкара тәҗрибә алмашу һәм үз мәктәпләрендә рус телен өйрәнү темасын күтәргәннәр. Хәзерге вакытта бөтен дөнья буйлап 62 илдә 60 тан артык рус теле үзәге ачылган. 30 илнең мәктәпләренә рус теле һәм әдәбияты укытучылары җибәрелде. Моннан тыш, анда алмашу буенча табигый фәннәр укытучыларын җибәрергә планлаштыралар.

Соңыннан форумда катнашучылар Казан федераль университеты һәм Иннополис, Татарстанның төп тикшеренү вузлары, шулай ук колледжлар, лицейлар, «Адымнар» мәктәпләре һәм хәтта балалар бакчалары тәҗрибәсен өйрәнделәр. Делегатлар өчен практик һәм теоретик өлештән тыш, танып белү күргәзмәсе дә оештырылды. Анда илнең 30 дан артык оешмасында белем бирүнең иң яхшы тәҗрибәләре турында тәкъдим ителгән иде. Очрашу мәгариф министрларының «Артек» халыкара балалар үзәгенең 100 еллыгына багышланган телекүпер белән тәмамланды.

Фәния ЛОТФУЛЛИНА

УЧИТЕЛЕЙ В ОБИДУ НЕ ДАДИМ!

Учительство всегда считалось одной из самых значимых профессий в обществе. Оно формирует новое поколение и, по сути, определяет будущее любого государства. Однако в условиях современной реальности учителя сталкиваются с непростыми вызовами. Моральные и материальные аспекты некогда самой уважаемой профессии сегодня требуют поддержки и защиты со стороны государства, правовых и профсоюзных организаций.



«У педагога есть не только обязанности, но и права», – говорит руководитель Татарстанской республиканской организации Общероссийского Профсоюза образования **Ирина Проценко**. Поэтому все их усилия направлены на то, чтобы обеспечить достойный уровень заработной платы и ее индексацию, а также соблюдение трудовой безопасности и благополучие педагогов.

УЧИТЕЛЬ СЕГОДНЯ КАК НИКОГДА НУЖДАЕТСЯ В ЗАЩИТЕ

– Ирина Николаевна, роль учителя в обществе всегда была основополагающей. Однако сегодня педагог зачастую находится в уязвимом положении. На него возлагается множество обязанностей, а о его правах многие даже не задумываются...

– Учитель – самая главная фигура в жизни любого государства. И если говорить об уязвимости учителей в современных условиях, то, наверное, это связано с тем, что в 90-е годы многое было утрачено в отношении представителей данной профессии. Сейчас почему-то родители перекладывают воспитание детей на детские сады, школы. Начинают диктовать, как должен работать учитель, какие оценки имеет право ставить и т.д.

Наша профсоюзная организация как раз и следит за тем, чтобы учитель был не только «должен», но и «имел право».

– С чем, по Вашему мнению, связана утрата престижа профессии учителя?

– Первая причина – это низкая заработная плата. Вторая, скорее, моральная. Сегодня стало сложнее работать не столько с детьми, сколько с их родителями. Им трудно объяснить, что над воспитанием, образованием ребенка должны работать

обе стороны: и школа, и семья. Работая на две ставки, в две смены, на родительском собрании вместо благодарности услышать только вопросы: «Почему мой ребенок учится плохо?» или «Почему вы ему поставили двойку?» – вот факторы, которые негативно сказываются на престиже профессии учителя. Раньше статус учителя был гораздо выше.

– Сегодня мы становимся свидетелями различных конфликтных ситуаций, в которых задействованы учитель – руководство учебного заведения, учитель – ученик, учитель – родитель. И как будто бы всегда виноватой стороной остается именно учитель. Почему, по Вашему мнению, так происходит?

– В конфликте не бывает задействована только одна сторона. Конфликт – это всегда взаимодействие двустороннее, поэтому и вина ложится, наверное, и на ту, и на другую сторону. Но здесь самое главное – правильно разобрать конфликт. В сегодняшних реалиях стало сложнее разговаривать с родителями, почему-то они перестали слышать педагога. Вот это, конечно, очень печально. Потому что ни одна школа не учит плохому, ни один учитель не желает плохого своим ученикам. Но, когда доходит до того, что дети позволяют себе унижать педагога или родители позволяют себе оскорблять учителя, вот тогда уже все общество должно становиться на защиту учителя. Как я уже говорила, в любой ситуации надо разбираться. Нельзя винить только одну сторону.

ПРОФСОЮЗЫ СЛУШАЮТ И СЛЫШАТ

– Ирина Николаевна, расскажите, пожалуйста, в чем сегодня состоит основная задача профсоюзной организации?

– Основной задачей профсоюза всегда была защита социально-трудовых прав, гарантий, соблюдение норм законодательства. Если говорить проще, мы следим за тем, чтобы все законы, которые касаются нашей бюджетной сферы образования, исполнялись. Это и федеральные законы, и республиканские. Контроль за материальным благополучием педагога, защищенность и контроль в области охраны труда, в правовых вопросах являются нашим приоритетом. Профсоюзные юристы готовы оказать правовую помощь членам профсоюза абсолютно бесплатно, вплоть до представления интересов в суде.

– Сколько татарстанских учителей сейчас состоят в профсоюзе?

– 96 процентов работников нашей отрасли – члены профсоюза. Если перевести в цифры, то это больше 174 тысяч. Сюда входят и педагоги со стажем, и молодые специалисты. Такой охват позволяет нам иметь крепкую позицию в государственно-общественном управлении, быть услышанными во властных структурах, а как следствие – добиваться улучшений норм труда, повышать материальное благосостояние наших членов профсоюза, отслеживать, чтобы права и интересы работников образования не нарушались.

– Насколько часто учителя обращаются к вам за защитой своих прав?

– Обращений очень много, порядка 10 тыс. обращений разного характера в год. Но основные вопросы – это вопросы по заработной плате. К примеру, в январе 2024 года сложилась ситуация, когда базовые оклады педагогов Татарстана впервые оказались ниже МРОТ. Профсоюз не был молчаливым наблюдателем этого процесса, мы реагировали, формировали позицию, разъясняли, и совместно с Министерством образования и науки, Федерацией профсоюзов республики, при поддержке Раиса РТ Р.Н. Минниханова тогда этот вопрос удалось решить.

– Сейчас у многих педагогов период отпусков. Нет ли нарушений в начислении отпускных?

– По отпускным у нас проблем не возникало до прошлого года.